РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАМАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423643, РТ, Менделеевский район, с.Камаево, ул. Дифгата Сирая д.29А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423643 , РТ, Менделеевск районы, Камай авылы, Дифгать Сирай урамы 29А йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

2026 елның 28 августыннан N 31

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Камай авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛА:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының 2022 ел 18 октябрендәге 65 номерлы карары белән расланган Камай авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 статьясын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Статья 2. Депутат вәкаләтләре чоры

1. Депутат вәкаләтләре ул сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының тулы хокуклы составтагы беренче утырышын уздырган көннән туктатыла..

2. Депутат вәкаләтләре чоры "авами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының "Камай авыл җирлеге“ муниципаль берәмлеге Уставы белән билгеләнә.

1.2. Нигезләмәнең 3 статьясындагы 1 өлешен үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат вәкаләтләре вакытыннан алда түбәндәге очракта туктатыла:

1) вафат булганда;

2) үз теләге белән отставкага киткәндә;

3) суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылганда;

4) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылу яисә вафат дип игълан ителгәндә;

5) аңа карата судның гаепләү хөкеменең законлы көченә кергәндә;

6) даими яшәү урынына Россия Федерациясеннән читкә киткәндә;

7) Россия Федерациясе гражданлыгын туктатылганда, яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт гражданлыгы (гражданлыгы) яки яшәүгә рөхсәте , яисә чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукынраслый торган башка документы булганда;

8) җирле үзидарәнең тиешле органы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктылганда;

9) хәрби хезмәткә чакырылганда, яисә аны алмаштыручы альтернатив граждан хезмәтенә юллама булганда;

10) чит ил агенты статусын алганда;

11) әлеге Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән башка очракларда.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтының www.mendeleevsk.tatar.ru "Камай авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Камай авыл җирлеге Советы Рәисе И.М.Ахунҗанов